РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» декабрь 2024 ел г. Альметьевск № 4142

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган Әлмәт муниципаль районының аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә хезмәте хакы түләү шартлары турында» 2018 елның 25 июнендәге 864 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

«Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 21 сентябрендәге 820 номерлы карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган Әлмәт муниципаль районының аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә хезмәте хакы түләү шартлары турында» 2018 елның 25 июнендәге 864 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 11 декабрендәге 1827 номерлы, 2022 елның 28 гыйнварындагы 99 номерлы, 2022 елның 17 мартындагы 419 номерлы, 2022 елның 26 сентябрендәге 2102 номерлы, 2022 елның 28 октябрендәге 2489 номерлы, 2022 елның 21 декабрендәге 3088 номерлы, 2024 елның 26 июнендәге2195 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. Карарга 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«25» июнь 2018 ел № 864

заказ № 1-851

карары белән расланган
1 нче кушымта

Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсендә аерым оешмалар җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Вазыйфаи окладларның күләме, сум |
|---|---|
| Мөстәкыйль идарә (бүлек) җитәкчесе | 19 027 |
| Мөстәкыйль идарә (бүлек) җитәкчесе урынбасары | 18 467 |
| Бүлек җитәкчесе | 17 768 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 16 928 |
| Баш белгеч | 16 089 |
| Алып баручы белгеч | 15 250 |
| I категорияле белгеч | 14 270 |
| II категорияле белгеч | 14 130 |
| Белгеч | 13 990 |

1.3. Карарга 2 нче кушымтадагы таблицада «13 323» санын «13 990» саннарына алмаштырырга.

2. Бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләренә аерым оешмалар хезмәткәрләренең өстәмә түләүләрен һәм башка түләүләрен билгеләү турында элек чыгарылган актларны әлеге карарга туры китерергә.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А. Ә. Ямалетдиновка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе Г.М. Хәбутдинова